| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.07.2019 Алексеевск ш.т.б. № 287

**Опека һәм попечительлек бүлеге тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

**карар бирәм:**

1. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын расларга:

ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча (Кушымта №1);

балигъ булмаганнар исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча (Кушымта №2);

Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын уллыкка алу һәм уллыкка алу хокукына кандидат буларак исәпкә кую мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча (Кушымта №3);

балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен алу буенча алыш-биреш ясауга алдан рөхсәт бирү буенча (Кушымта №4);

унд<br>үрт яшькә җитмәгән баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча (Кушымта №5);

ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарга (түләүле яки түләүсез шартларда опекага (попечительлеккә) билгеләү яки опекун (попечитель) булырга мөмкинчелек бирү турында бәяләмә алу буенча (Кушымта №6);

балигъ булмаганнарга эмансипация (балигъ булмаганнарны тулысынча эшкә сәләтле дип игълан итү) турында карар кабул итү буенча (Кушымта №7);

балигъ булмаган баланың күчемсез милекен алу буенча алыш-бирешләрне тормышка ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча (Кушымта №8);

кредит акчаларыннан файдаланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны балигъ булмаганнар катнашында залог итеп (ипотекага) тапшыру буенча (Кушымта №9);

балигъ булмаган балага акчалата ярдәм алуга законлы вәкилгә рөхсәт бирү буенча (Кушымта №10);

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

Башкарма комитет җитәкчесенең «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алган вакытта ятим балалар һәм попечительсез калган балалар арасыннан булган затларга акча билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты турында» 2012 елның 17 сентябрендәге 775 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Баланың исемен һәм (яки) фамилиясен үзгәртүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты турында» 2012 елның 17 сентябрендәге 774 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «14 яшьтән 16 яшькә кадәрге балаларны эшкә урнаштыру өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты турында» 2012 елның 17 сентябрендәге 772 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Эмансипация мөмкинлеге (баланы тулысынча эшкә сәләтле дип тану) турында карар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты турында» 2012 елның 17 сентябрендәге 771 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Гаиләләргә опекага (попечительлеккә) бирелгән балаларны карап тоту өчен акча билгеләү һәм түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты турында» 2012 елның 17 сентябрендәге 770 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Балигъ булмаганнарның акчаларын алу өчен законлы вәкилгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты турында» 2012 елның 17 сентябрендәге 769 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Балигъ булмаганнарның күчемле мөлкәтен алу буенча килешүләр ясауга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты турында» 2012 елның 17 сентябрендәге 767 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Кредит акчаларыннан файдаланып торак сатып алуга алдан рөхсәт бирү һәм аны балигъ булмаганнар катнашында залогка (ипотекага) тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты турында» 2012 елның 17 сентябрендәге 766 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Балигъ булмаганнар исеменнән сатып алуның өстенлекле хокукыннан баш тартуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт

хезмәте күрсәтүнең административ регламенты турында» 2012 елның 17 сентябрендәге 768 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Балигъ булмаганнарның хокукларына яки закон тарафыннан саклансыла торган мәнфәгатьләренә кагылышлы милекне, торак мәйданны башка затларга күчерү (сату, бүләк итү, алмашу һ. б.) буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты турында» 2012 елның 17 сентябрендәге 773 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарга (түләүле яки түләүсез шартларда опекага (попечительлеккә) билгеләү яки опекун (попечитель) булырга мөмкинчелек бирү турында бәяләмә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 886 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда булган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2013 елның 15 ноябрендәге 867 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алучылар сыйфатында исәпкә кую буенча хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2013 елның 15 ноябрендәге 868 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Балигъ булмаган балага караган күчемсез милекне алу буенча алыш-бирешләрне тормышка ашыруга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 869 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Опека һәм попечительлек бүлеге тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларына өстәмәләр кертү турында» 2016 елның 26 июлендәге 304 номерлы карары;

Башкарма комитет җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең «Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарга (түләүле яки түләүсез шартларда опекага (попечительлеккә) билгеләү яки опекун (попечитель) булырга мөмкинчелек бирү турында бәяләмә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 15 ноябрендәге 866 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 30 ноябрендәге 561 номерлы карары.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының http://alekseevskiy.tatarstan.ru. рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның опека һәм попечительлек бүлеге начальнигы Е. П. Гореловага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**